**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Әлки**
**муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
тел: тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

2018 елның 17 феврале 63№

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитеты каршында
Хатын - кызлар советын төзү турында

Җәмгыятьтә хатын-кызларның мәнфәгатьләрен яклау, иҗтимагый-сәяси, икътисадый, мәдәни тормышта аларның ролен күтәрү максатларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Хатын-кызлар советы төзергә.

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хатын-кызлар советын һәм аның составын яңа редакциядә расларга.

3. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 24 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Хатын-кызлар советын төзү турында» 168 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары М.А. Платоновага йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В. Юсупов

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның 17 февралендәге
63 номерлы карарына 1 нче
кушымта

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Хатын-кызлар советы СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| **Платонова М.А.** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Хатын-кызлар советы рәисе; |
| **Гайфуллина Р.А.** | «Әлки районы мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы, Хатын-кызлар советы рәисе урынбасары; |
| **Петухова Т.А.** | «Әлки авылара үзәк китапханәсе» МБУК директоры, Хатын-кызлар советы сәркатибы; |
| **А.А.Гайфуллина** | "Балалар иҗаты йорты" МБУ директоры (килешү буенча); |
| **Заһидуллина Н.Х.** | «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ методист-психолог (килешү буенча); |
| **Бухарова Е.В.** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе вазыйфаларын башкаручы; |
| **Җәләлова М.Г.** | Татарстан Республикасы ФМ Казначылык департаментының Әлки районы буенча территориаль бүлеге җитәкчесе(килешү буенча); |
| **Углева С.С.** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы; |
| **Хәлиуллина Э.Ф.** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге начальнигы; |
| **Васяйчева Е.В.** | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге начальнигы; |
| **Л. Я. Низамиева** | «Әлки хәбәрләре» газетасы редакциясе |

| | |
|---|---|
| | бүлеге мөхәррире (килешү буенча); |
| **Сәгыйтова Г.Ю.** | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| **Аверьянов О.Н.** | Хузангай урта мәктәбе директоры ( килешү буенча); |
| **Г.Ш. Давлеева** | шәхси эшмәкәр (килешү буенча); |
| **Төхвәтулина Г.Х.** | шәхси эшмәкәр (килешү буенча); |
| **Ибәтова А.Н.** | җәмәгатьчелек вәкиле; |
| **Вафина Ф.Б**. | җәмәгатьчелек вәкиле |

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитетының 2018 елның 17 февралендәге
63 номерлы карарына 2 нче
кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хатын-кызлар советы турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хатын-кызлар советы (алга таба - Хатын-кызлар советы) Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы гражданлык җәмгыяте институтларын алга таба үстерү, Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хатын-кызлар һәм балалар мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, иҗтимагый-сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышта хатын-кызларның ролен күтәрү, шулай ук җирлек муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә Хатын-кызлар советы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен төзелгән коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

1.2. Хатын-кызлар советы гаилә институтын торгызу, гаилә иминлеге өчен гражданлык җаваплылыгы, хатын-кызлар һәм балалар хокукларын тану һәм үтәү турында җәмәгатьчелек фикерен үстерүдә хезмәт итәргә тиеш.

1.3. Хатын-кызлар советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон актлары, Әлки муниципаль районы Уставы һәм муниципаль хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Хатын-кызлар советы эшчәнлеге хәбәрдарлык һәм ачыклык, фикер төрлелеге һәм демократия принципларында этика нормаларын үтәгән хәлдә тормышка ашырыла.

## 2. Хатын-кызлар советы бурычлары

2.1. Хатын-кызлар советының төп бурычлары:

- хатын-кызларның һәм балаларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүдә катнашу;
- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә хатын-кызларның һәм балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу турында системалы мәгълүмат җиткерү;
- җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга ярдәм итә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклауда катнашу, хокук саклау органнарына мәгълүмат җиткерү;
- халыкның мәдәни дәрәҗәсен күтәрүдә катнашу;
- гаилә институтын ныгыту, ана булу дәрәҗәсен күтәрү;
- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каравына Әлки муниципаль районы территориясендә аналар һәм балалар проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм кертү;

- балаларның гармонияле үсүенә, матди һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә, патриотик һәм гуманистик фикерләүгә шартлар тудыруга ярдәм итү;

- гаилә сәясәте, белем алу, мәдәният, сәламәтлек саклау, халыкны социаль партнерлык нигезендә социаль яклау мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек;

- Россия Федерациясенең милли иминлеге нигезе буларак имин гаиләгә юнәлдерелгән дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының гаилә сәясәтен пропагандалау һәм популярлаштыру;

- аналар һәм балалар мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тиешле тәкъдимнәр әзерләү;

- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдиме буенча Хатын-кызлар советы компетенциясенә кагылышлы башка мәсьәләләр буенча фикер алышу;

- гаилә сәламәтлеге, ана һәм балаларны социаль яклау, хатын-кызларның социаль хокуклары мәсьәләләре буенча агарту һәм консультация эшчәнлегенең төрле рәвешләрен оештыру;

- массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлекне оештыру, телечыгышлар, күргәзмәләр, лекторийлар, башка мәдәни-агарту чаралары оештыру;

- Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарына гаилә сәясәте өлкәсендәге процесслар һәм тенденцияләр турында мәгълүмат җиткерү, алар буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- хатын-кызларны социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итүгә юнәлдерелгән очрашулар, җыелышлар һәм башка чаралар оештыру һәм уздыру.

2.2. Хатын-кызлар советы шәхси мәсьәләләр, шул исәптән милек, торак һәм хезмәт бәхәсләре белән бәйле, шулай ук судларның, тикшерү органнарының карарларына шикаятьләр белән дә мөрәҗәгать итми.

## 3. Хатын-кызлар советы хокуклары

3.1. Үзенә йөкләнгән бурычларны башкару өчен Хатын-кызлар советы хокуклы:

- җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, муниципаль предприятиеләрдән һәм учреждениеләрдән, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

- үз утырышларына Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларын, иҗтимагый берләшмәләре вәкилләрен чакырырга;

- җирле үзидарә органнары, Әлки муниципаль районының Хатын-кызлар советы компетенциясенә керә торган проблемалар буенча иҗтимагый берләшмәләре уздыра торган киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

- фикер алышу һәм хәл итү әлеге Нигезләмәнең 2.1 п. нигезендә Хатын-кызлар советы бурычларын нәтиҗәле үтәүгә йогынты ясарга мөмкин булган, шулай ук хатын-кызлар һәм балалар хокукларына һәм мәнфәгатьләренә, гаилә институтына һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы мәсьәләләр буенча

конференцияләр, киңәшмәләр һәм семинарлар әзерләүдә һәм уздыруда катнашу, турыдан-туры катнашырга.

3.2. Хатын-кызлар советы әгъзалары эшчәнлеге түләүсез нигездә алып барыла.

3.3. Хатын-кызлар советы үз эшчәнлеген аның әгъзалары һәм Әлки муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең уртак карары белән туктатылырга мөмкин.

## 4. Хатын-кызлар советы эшен оештыру

4.1. Хатын-кызлар советы турындагы нигезләмә һәм аның составы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

4.2. Хатын-кызлар советын Хатын-кызлар советы рәисе җитәкли, ә ул булмаганда - рәис урынбасары. Хатын-кызлар советы сәркатибы Хатын-кызлар советы эшен оештыру-техник яктан тәэмин итә.

4.3. Хатын-кызлар советы рәисе, аның урынбасары һәм сәркатибы Хатын-кызлар советы утырышында турыдан-туры аның составыннан сайлана.

4.4. Совет рәисе:

- Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;
- Хатын-кызлар советы эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели һәм раслый;
- Хатын-кызлар советы утырышларын уздыру урынын һәм вакытын билгели;
- Хатын-кызлар советы утырышларында рәислек итә.

4.5. Хатын-кызлар советы утырышын рәис булмаганда Хатын-кызлар советы рәисе урынбасары алып бара.

4.6. Хатын-кызлар советы сәркатибы:

-Хатын-кызлар советы әгъзаларына Хатын-кызлар советы утырышларын уздыру урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә,Хатын-кызлар советы утырышларында фикер алышу өчен кирәкле мәгълүматны (күбесенчә электрон рәвештә) җибәрә;

- Хатын-кызлар советы утырышлары материалларын оештыру әзерлеген тәэмин итә;
- беркетмә алып баруны тәэмин итә;
- Хатын-кызлар советы рәисе йөкләмәләрен үти.

4.7. Хатын-кызлар советы әгъзалары:

- Хатын-кызлар советы утырышына чыгарылган мәсьәләләрне әзерли һәм алдан карый;
- Хатын-кызлар советы эше планы буенча тәкъдимнәр кертәләр;
- Хатын-кызлар советы утырышында катнашалар.

4.8. Хатын-кызлар советы үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегендә бәян ителгән бурычлар һәм Хатын-кызлар советы карары белән раслана торган еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

4.9. Хатын-кызлар советы утырышы кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк очракта Хатын-кызлар советының чираттан тыш утырышы үткәрелергә мөмкин.

4.10. Хатын-кызлар советы утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.11. Хатын-кызлар советы әгъзалары Хатын-кызлар советы утырышларында шәхси катнаша. Хатын-кызлар советы әгъзаларына аларның вәкилләре рөхсәт ителми.

4.12. Хатын-кызлар советы карарлары утырышта катнашучы Хатын-кызлар советы әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Хатын-кызлар советы әгъзаларының барысы да хәлиткеч тавыш хокукына ия. Тавышлар тигез булганда хәлиткеч тавыш хокукына Хатын-кызлар советы рәисе ия, ә ул булмаса -Хатын-кызлар советы утырышында рәислек итүче Хатын-кызлар советы рәисе урынбасары.

4.13. Хатын-кызлар советы карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул рәислек итүче тарафыннан имзалана.

4.14. Хатын-кызлар советы карарлары рекомендация характерында. Кабул ителгән карарлар, тәкъдимнәр турындагы мәгълүмат Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе игътибарына җиткерелә.

4.15. Хатын-кызлар советы утырышларына шулай ук дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка кызыксынган оешмалар вәкилләре, экспертлар, белгечләр, галимнәр, башка кызыксынучы затлар чакырылырга мөмкин. Чакырылган затлар карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнаша һәм үз тәкъдимнәрен кертә ала.

4.16. Рәислек итүче карары буенча Хатын-кызлар советы утырышында кабул ителгән мәсьәләләр һәм карарлар җәмәгатьчелеккә массакүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерелергә мөмкин.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Хатын-кызлар советы әгъзалары тәкъдиме буенча кертелә һәм аерым карар белән Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.